**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№34** **21 июль 2021 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 10 нче декабрендәге 15 нчы номерлы «Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең 2021 нчы елга һәм 2022, 2023 нче елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 10 нче декабрендә кабул ителгән 15 нчы номерлы "Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең 2021 нчы елга һәм 2022, 2023 нче елларның планлы чорына бюджеты турында", (11.06.2021 29 номерлы корары үзгәрешләре белен) елныкарарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә "5080,9" санын "5708,9" санына алмаштырырга;

б) 2 өлештә "5090,9" санын "6221,1" санына алмаштырырга;

в) 3 өлештә "10,0" санын "512,2" санына алмаштырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2021 елга Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары" кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм редакцияне әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә бәян итәргә.;

1.3. “2021 елга Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге бюджетының фаразланган керемнәр күләме" 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә редакцияне бәян итәргә.;

1.4. «2021 елга Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 5 нче кушымтасының 1 нче

таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә редакцияне бәян итәргә.;

1.5. «Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча бүлү» 6 нчы кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә.;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Яңа Спас авыл җирлеге**
**Советы башлыгы** **Н.В.Танчук**